ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МЕНЗЕЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

11.12.2018 г.Мензелинск № 1386

**Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль район Башкарма комитеты җитәкчесенең 15.06.2009 елдагы “Юбилейный” балалар һәм үсмерләр спорт мәктәбе Уставын салым органында кабаттан теркәү өчен “Юбилейный” балалар һәм үсмерләр спорт мәктәбе” балаларга өстәмә белем бирү муниципаль учреждениесенең исемен үзгәртү турында”гы №444 Карарына үзгәрешләр кертү турында**

08.10.2018 елдагы “Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль район Бшакарма комитетына караган муниципаль казна учреждениеләре һәм муниципаль унитар предприятиеләр, муниципаль учреждениеләрнең Уставларына, мәнфәгатьләр каршылыгына китерүче яисә китерү куркынычы булган вазифаи бурычларны башкарганда шәхси кызыксынучанлык туу турында хәбәр итү бурычын билгеләүче үзгәрешләргә тиешле учреждениеләр (предприятиеләр) җитәкчеләре һәм хезмәткәрләре белән хезмәт килешүләренә мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау һәм җайга салу мәсьәләләрен җайга салучы үзгәрешләр кертү турында”гы №1136 карары, шулай ук 25.12.2008 елдагы “Коррупциягә каршы тору турында”гы №273-ФЗ Федераль Закон нигезендә, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль район Башкарма комитеты

КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1.Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының “Юбилейный” Балалар-үсмерләр спорт мәктәбе” өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе Уставына үзгәрешләр кертергә:

“Белем бирү процессында катнашучыларның хокуклары һәм бурычлары” IV Бүлеген “Мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау һәм җайга салу” 4.9 пункты белән тулыландырырга.

4.9.1.Учреждение хезмәткәренең шәхси кызыксынучанлыгы аларның вазифаи бурычларын тиешенчә башкаруга тәэсир итәргә мөмкин булган һәм (яисә) хезмәткәрнең шәхси кызыксынучанлыгы белән үзе эшли торган учреждениенең хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре арасында

учреждениенең мөлкәтенә һәм эш репутациясенә каршылыклар килеп чыгуга китерүче вәзгыять мәнфәгатьләр каршылыгы дип атала.

4.9.2.Учреждение хезмәткәренең вазифаи бурычларын башкаруга бәйле рәвештә акчалата, байлыклар, башка мөлкәт рәвешендә, шул исәптән, үзе һәм өченче затлар өчен мөлкәткә хокуклар һәм мөлкәт характерындагы хезмәтләр күрсәтү белән бәйле рәвештә, акчалата керем алу мөмкинлеге
учреждение хезмәткәренең вазифаи бурычларын тиешенчә үтәвенә тәэсир иткән яисә тәэсир итү куркынычы булырлык шәхси кызыксынуы дип аңлатыла.

4.9.3. ”Юбилейный” балалар һәм үсмерләр спорт мәктәбе директоры ТР Минзәлә муниципаль район Башкарма комитеты Җитәкчесенә вазифаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерүче һәм китерү куркынычы булган шәхси кызыксыну килеп чыгу турында хәбәр итәргә бурычлы.

4.9.4. ”Юбилейный” балалар һәм үсмерләр спорт мәктәбе хезмәткәре учреждение директорына вазифаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерүче һәм китерү куркынычы булган шәхси кызыксыну килеп чыгу турында хәбәр итәргә бурычлы.

4.9.5. ”Юбилейный” балалар һәм үсмерләр спорт мәктәбе директорына хәбәр итү тәртибе, рәсми хәбәрләрдә булган мәгълүматлар исемлеге, әлеге мәгълүматларны тикшерүне һәм рәсми хәбәрләрне теркәү тәртибе Юбилейный” балалар һәм үсмерләр спорт мәктәбе директоры тарафыннан билгеләнә.

2. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының “Юбилейный” Балалар һәм үсмерләр спорт мәктәбе” муниципаль бюджет учреждениесе Уставына үзгәрешләр кертүне уздыру буенча вәкаләтле зат итеп “Юбилейный” Балалар һәм үсмерләр спорт мәктәбе” муниципаль бюджет учреждениесе директоры Ф.Г.Хизбуллинны билгеләргә.

3. Гамәлдәге карарның үтәлешен контрольдә тотуны мәгариф, мәдәният, сәламәтлек саклау, яшьләр эшләре, спорт һәм социаль мәсьәләләр буенча комиссиягә йөкләргә.

ТР Минзәлә муниципаль район
Башкарма комитет җитәкчесе
вазифаларын башкаручы А.Г.Гатина